ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

2021 ел 18 ноябрь Иске Чүпрәле № 6

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Чүпрәле авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 15.10.2019 ел, № 59/3 карары (15.11.2019 ел, № 60/6 редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе» нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегенең Яңа Чүпрәле торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 6 декабренә 14.30 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы,Үзәк урамы, 9 йорт Район мәдәният йорты; адресы буенча беренче этап гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегенең Яңа Чүпрәле торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 6 декабренә 15.30 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы,Үзәк урамы, 9 йорт Район мәдәният йорты; адресы буенча икенче этап гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибен территориаль билге буенча билгеләргә.

4. Халыктан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабына кертергә киләсе урамнар: Энергетиклар тыкрыгы, Энергетиклар ур., Заречная 2-нче йорт, Полевая ур., Заовражная ур., С. Сәйдәшев ур. Химиклар ур., 1 нче Химиклар тыкрыгы, 2 нче Химиклар тыкрыгы, 3 нче Химиклар тыкрыгы, Заречная 1-нче ур.

5. Халыктан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабына кертергә киләсе урамнар: Колхоз урамы, Яшьләр ур., Яшьләр пр., Совет ур., Мәдәни ур. Комсомол урамы, Спорт урамы, Тукай урамы, Гагарин урамы.

6. Гражданнар җыенында түбәндәге мәсьәләне расларга:

"2022 елда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Яңа Чүпрәле авылында урамнарны яктыртуне төзәтүгә;
- Колхоз урамыннан зиратка кадәр; Заовражная урамы буенча Яңа Чүпрәленең гамәлдәге юлларын вак ташлау;
- Яңа Чүпрәледә зиратларны карап тоту;
- Яңа Чүпрәле авылында иске агачларны кисү;
- Яңа Чүпрәле авылы,Колхоз,Гагарина,С.Сайдашев,урамнарына ясалма юл тигезсезлеге урнаштыру.

«ӘЙЕ» «ЮК»

9. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Иске Чүпрәле авыл җирлеге
Башлыгы Урынбасары: Р.Д.Низамов